# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Илексаз  авыл җирлегенең Илексаз  авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 15 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз  авыл җирлегенең Илексаз  авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз  авыл җирлеге Илексаз  авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән  300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Илексаз авылында юл корылмаларын буяу өчен буяу, юл тамгасы ясау;
- Илексаз авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);
- Илексаз авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилейлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;
- Илексаз авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
- Илексаз авылында ял итү зонасын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- Илексаз авылында ял итү зонасы мәйданчыгына кара балчык ташу;
- "Илексазым-моңлы сазым"логотибы төшерелгән постамент өчен материаллар сатып алу;
- Илексаз  авылы урамнарын  яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар алу);
- Илексаз авылы зиратына инвентарь, техника өчен запас частьлар сатып алу;
- тракторга кар аттыру өчен тагылма сатып алу;
- янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар (мотопомпалар өчен запас частьләр) сатып алу.

3. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Гыйлфанов Ф.М.